| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның 30 июне Алабуга шәһәре № 173

Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы "Муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия турында нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы кодексы, Алабуга муниципаль районы Советының 2008 елның 26 февралендәге 157 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымта Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 6 сентябрендәге «Муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» гы 294 нче карарына кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы «Муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында " гы 2021 елның 10 июнендәге 79 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль төзелеш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары О.Е. Колпаков

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Советы карары буенча
2022 елның «30» июня
№173

Муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия
исемлеге

Комиссия рәисе
Алабуга муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе;

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары;

Алабуга муниципаль районы советының кадрлар белән эшләү секторы мөдире;

Комиссия әгъзалары:

"Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы"МКУ рәисе;

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы.